9·10
2004

Признан победителем и награжден грантом "Фонда Сороса"

Издается с 12 апреля 1994 года

НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ



Сабыйга

№ 9-10 (123-124) — 2004 ел
(сентябрь-октябрь)

Мәктәпкәчә
яшьтәге һәм кече
яшьтәге мәктәп балаларының
әдәби-нәфис журналы

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫҺӘМ ФӘННИ-ИҖАДИМАТДИ ХИМАЯЧЕ ЮРИДИК ЗАТЛАР:
Редакция коллективы, Казан шәһәре хакимияте, Телләрне һәм мәдәниятләрне үстерүче «Өмет» шәһәр Фонды, академик «Мирас» журналы редакциясе, Татар «Мирас» Фонды, Россия Гуманитар Фәннәр академиясе, Россия язучылары Союзы, Татар язучылары Союзы

Баш редактор
МИҢНӘХМӘТ СӘХАПОВ

Редакция советы:
Алла Айсина
Ирек Арсланов
Марсель Әхмәтҗанов
Әлфия Галимҗанова
Җәүдәт Дәрзаман
Айрат Зарипов
Фирдәвес Зарифуллин
Камил Исхаков
Сергей Михалков
Энгель Таһиров
Лилия Сәхапова
Булат Солтанбеков
Ленар Сәлахов
Вахит Хаков
Заһир Хәкимов
Зөфәр Хәкимов
Әнәс Хәсәнов

Тышлыкта Светлана Фәттахова рәсемнәре.

«Сабыйга» балалар журналының индексы — **73954**. Аңа Татарстан Республикасының, Русия Федерациясе составында булган республикаларның, край һәм өлкәләрнең, БДБ составына кергән дәүләтләрнең һәм чит илләрнең элемтә бүлекләрендә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Журнал татар һәм урыс телләрендә нәшер ителә. Редакциянең адресы: 420066; Казан шәһәре, Чистай урамы, 5 йорт. Бәйләнешкә керү өчен телефон: *(8432)* **92-35-54**. Журналга язылу һәм аны тарату мәсьәләләре буенча 38-59-78 номерлы телефон аша мөрәҗәгать итәргә, ә басманың сыйфатына кагылышлы дәгъваларны исә 43-27-73 номерлы телефон ярдәмендә белдерергә мөмкин. Иганәчеләр өчен журналның исәп-хисап саны **р/с № 40603810900020000105** Ачык типтагы акционерлар җәмгыяте статусындагы «Ак Барс» Банкында. Корр. счеты № 30101810000000000805. Журнал идеясенең, концепциясенең һәм исеменең авторы М. Җ. Сәхапов.

Гигиена сертификаты № 16.09.01. 952.П.0000 74.01.01, 24.01.2001 ел.

«Сабыйга» журналы Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 314 сан белән теркәлде. 1994 елның 12 апреленнән бирле нәшер ителә.

Производствога бирелде 3.06.2004 ел. Басарга кул куелды 2.08.2004 ел. Форматы 84x108 /16. Офсет кәгазе № 1. Күләме 5.50 басма табак. 5,55 нәшер-хисап табак. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 6000 данә. Заказ Э-485. Ваклап сатуда ирекле бәя.

«Идел-Пресс» дәүләт унитар предприятиесенең полиграфия-нәшрият комплексы. 420066; Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт.


© «Сабыйга», 2004 ел.

СЕНТЯБРЬ

Сентябрьнең аяз иртәсендә
Дәвам итә ашлык сугулар.
Диңгез аръягына кошлар китә,
Мәктәпләрдә гөрли укулар.

ОКТЯБРЬ

Октябрьдә, октябрьдә,
Яңгыр туктамый бер дә.
Үләннәр үсеп туктаган,
Чикерткәләр күптән тынган.
Кышын мичкә ягарга дип,
Утыннар өеп куелган.



Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ

СЕНТЯБРЬ

Ясным утром сентября
Хлеб молотят сёла,
Мчатся птицы за моря —
И открылась школа.

ОКТЯБРЬ

В октябре, в октябре
Частый дождик на дворе.
На лугах мертва трава,
Замолчал кузнечик.
Заготовлены дрова
На зиму для печек.



Художник ЗУФАР ХАКИМОВ

Сабыйга

№ 9-10 (123-124) — 2004 г.
(сентябрь-октябрь)

Литературно-художественный журнал для детей старшего дошкольного и младшего школьного возрастов

УЧРЕДИТЕЛИ И СПОНСОРЫ:
Коллектив редакции, Администрация г. Казани, Городской Фонд развития языков и культуры «Өмет» («Надежда»), редакция академического журнала «Мирас», Российская Академия Гуманитарных наук, Союз российских писателей, Союз татарских писателей

Главный редактор
МИНАХМЕД САХАПОВ

Совет редакции:
Алла Айсина
Ирек Арсланов
Марсель Ахметзянов
Альфия Галимзянова
Джавдат Дарзаманов
Айрат Зарипов
Фирдаус Зарифуллин
Камиль Исхаков
Сергей Михалков
Энгель Тагиров
Лилия Сахапова
Булат Султанбеков
Ленар Салахов
Вахит Хаков
Загир Хакимов
Зуфар Хакимов
Анас Хасанов

На обложке рисунки Светланы Фаттаховой.

Индекс детского журнала «Сабыйга» — **73954.** Подписка на журнал производится без каких-либо ограничений во всех отделениях* связи Республики Татарстан, в областях, краях, республиках Российской Федерации, в государствах Ближнего и Дальнего Зарубежья. Журнал выходит на татарском и русском языках. Адрес редакции: 420066; г. Казань, ул. Чистопольская, 5; а/я № 227. Тел.: *(8432)* **92-35-54.** По вопросам доставки и подписки обращаться по телефону 38-59-78, качества печати 43-27-73. Для спонсоров журнала: **р/с № 40603810900020000105** в ОАО «Ак Барс» Банке, кор. счет № 30101810000000000805. БИК 049205805. ИНН № 16554002150. КПП 165501001. Код ОКОНХ — 87100, код ОКПО — 12986213. Автор идеи, концепции и названия журнала М. Ж. Сахапов.

Гигиенический сертификат № 16.09.01.952. П.0000 74.01.01, от 24.01.2001 г.

Журнал «Сабыйга» зарегистрирован в Мининформпечати РТ. Свидетельство № 314. Выходит с 12 апреля 1994 года.

Сдано в производство 3.06.2004 г. Подписано в печать 2.08.2004 г. Формат 84x108/16. Офсетная бумага № 1. Объем 5.50 п.л. Учетн.-изд. л. 5,55. Печатается офсетным способом. Тираж 6000 экз. Заказ Э-485. Цена договорная.

ГУП ПИК «Идел-Пресс». 420066; г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Сабыйга», 2004 г.



Кол Гали

КЫЙССАИ ЙОСЫФ

(ПОЭМА)

ЙОСЫФНЫҢ ТӨШЕ


Гъәзиз Йосыф тәмам унбер яшәр иде,
Йагъкуб сәүче тезләрендә йоклар иде,
Йоклаганда бер гаҗәп төш Йосыф күрде,
Юралышын атасыннан сорый инде.

«Туар кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз —
Барсы миңа төшемдә баш иде төп-төз,
Бу төшемне шулай күрдем һичбер шиксез,—
Йә әткәем, шуны миңа юра инде.


Бу төшемнең чын мәгънәсен ачып бир син,
Ахырда ни булачагын әйтеп бир син,
Юралышын миңа күркәм итеп бир син,
Бу төшемнең аслын изге сана инде».

Анда Йагъкуб Йосыфының төшен юрады,
Төш мәгънәсен сөенечкә әйтеп бирде:
«Өмет итәм: мәүләбездән ярдәм инде —
Сиңа олуг мәртәбәләр күрнә инде.

(Дәвамы бар.)



Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМ



Художник ЗУФАР ХАКИМОВ



Кул Гали

СКАЗАНИЕ О ЙУСУФЕ

(ПОЭМА)

СОН ЙУСУФА

Одиннадцати лет был праведный Йусуф,
Когда к Йакубу он прильнул, слегка вздремнув,
И он увидел сон, уже совсем уснув,—
«Отец,— сказал он,— сон мне истолкуй теперь.

Блеск солнца и луны увидел я во сне,
Одиннадцати звезд свет видел в вышине,
И все они земной поклон отдали мне.
Таков мой сон. Его ты истолкуй теперь.

Виденью моему истолкованье дай,
Что станется со мной — об этом знанье дай,
Во благо и в добро мне предсказанье дай,—
Пусть этот сон пошлет надежду мне теперь!»

Тогда истолковал Йакуб Йусуфа сон:
«Тебе,— он произнес,— во благо будет он,
Ты милостью творца да будешь одарен,
Тебя ждут слава, власть,— надеюсь я теперь.

(Продолжение следует.)



КАКТУСНЫҢ НИГӘ ЭНӘЛӘРЕ БАР?

Кактус — хайван яки үсемлекнең, исән калу өчен, климатка җайлашуының искиткеч мисалы.

Кактуслар — коры, эссе климатта яшәүче һәм озак вакыт сусыз торучы үсемлек. Климат корырак була баргач, кактусның тамырлары тирәнгә түгел, ә киңлеккә үсә башлый. Шуңа күрә ул, яңгырлар явуга ук, җир өслегендәге суны тиз генә суырта алган.

Әмма кактус әле бу суны сакларга да тиеш булган. Моңа кактусның болыт (губка) кебек күзәнәкле сабагы ярдәмендә ирешелә. Өстәвенә, үсемлекнең тышчасы, су парга әйләнмәс өчен, калын һәм каты.

Башка үсемлекләрнең кояш яктысында суны җиңел бирүче яфраклары бар. Ә кактусның яфраклар урынына энәләр, алар суны югалтудан саклыйлар. Энәләр үсемлекнең гомерен башка юл белән дә саклыйлар әле. Чүлдә сусызлыктан тилмереп йөрүче хайванны күз алдына китерегез. Ә кактус су белән тулган! Әмма бу хайванның чәнечкеле үсемлекне ашавын күз алдына да китереп булмый.

Дымны сакларга булышучы үзенчәлекле структурасына карамастан, кактус даими чәчәк атучы һәм җимешләр бирүче үсемлек.

Чын кактусларның ватаны — көнбатыш ярымшар. Алар нигездә Көньяк Американың, Үзәк Американың коры җирләрендә һәм АКШның көньяк-көнбатышында үсәләр.

Рәссам АЛЛА АЙСИНА

ПОЧЕМУ У КАКТУСА ИГОЛКИ?

Кактус — это замечательный пример того, как животное или растение приспосабливается к климату, если хочет выжить.

Кактусы — растения, которые живут в сухом, жарком климате и находятся без воды длительное время. Климат становился суше, корни кактуса стали расти не в глубину, а в ширину. Поэтому кактус мог быстро всасывать воду с поверхности земли сразу после того, как выпадут дожди.

Но кактус должен был хранить эту воду. Это достигается пористым, как губка, стеблем кактуса. К тому же оболочка растения толстая и грубая, чтобы вода не испарялась.

Другие растения имеют листья, которые легко отдают воду на солнечном свету. А у кактуса вместо листьев иголки — они предотвращают потерю воды. Иголки спасают жизнь растения ещё и другим путём. Представьте себе страдающее от жажды животное, бродящее по пустыне. А кактус полон воды! Но невозможно представить себе, как это животное ест растение в иголках.

Несмотря на свою специфическую структуру, помогающую сохранить влагу, кактус — это регулярно цветущее растение и дающее плоды.

Родина настоящих кактусов — западное полушарие. Они растут главным образом в сухих землях Южной Америки, Центральной Америки и юго-западе Соединённых Штатов.

Художник АЛЛА АЙСИНА



Әхлакый тәрбия

Каюм Насыйри

Китап • әти • тәрбия

ИЛЛЕ БИШЕНЧЕ ТӘРБИЯ

Әй угыл, бер кеше сине явыз холкы белән рәнҗетсә, эчкерсезлегең белән аңа вәгазь кыйл, ягъни аннан ачу алаем дип мәшәкать чикмә. Егетлек вә кешелеклелекнең тәмамендәндер ки, һәрни җәһәттән булса да, гайреләрдә булган хакыңны онытkайсән. Гайренең синдә булган хакын хәтереңдә тоткайсән, моны егетлек диерләр. Үч алырга вә җәза бирергә көч җитә торып гафу белән мөгамәлә кыйлмак барча изге холыкларның күркәмерәгедер.

Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМ

Каюм Насыри

Книга о воспитании



НАСТАВЛЕНИЕ ПЯТЬДЕСЯТ ПЯТОЕ

О сын мой, если кто-нибудь оскорбит тебя грубостью, не вздумай ответить тем же, лучше мягко пожури обидчика.

Твои великодушие и человечность лишь тогда проявятся до конца, если ты найдешь в себе силы забыть, чем обязаны тебе люди. Сам, однако, вечно будешь помнить их доброту. Это и есть истинное мужество.

Умение простить даже тогда, когда можешь наказать местью — вот самое прекрасное из человеческих достоинств.

Художник ЗАГИР ХАКИМОВ





ИКЕ МАЙМЫЛ БАЛАСЫ

(Һинд халык әкияте)

Бер шәһәрдә ике маймыл баласы яшәгән һәм алар бик зиһенсез икән. Икесе дә җимешләрне бик яраткан. Яратмаслыкмы соң, алар бик тәмле һәм файдалы бит: җимешләр ашасаң, матур һәм җитез буласың.

Бервакыт маймыл балалары урман буенча йөрергә чыгалар һәм анда өлгергән җимешле зур алмагачны күреп алалар. Аларның өйгә күбрәк алма алып кайтасылары килә. Әмма алмаларны кая салырга соң?

Маймыллар, як-якка карагач, энәләр тезелгән шарга охшаган түгәрәк әйбер күреп алалар. Алар, бик сөенеп, әлеге шарны өлгергән алмалар сибелгән җирдән тәгәрәтә башлыйлар. Инде бөтен алмалар энәләргә тезелгәч, шатланган маймыл балалары, агачка үрмәләп, иң яхшы алмаларны үзәләр дә аска ташлыйлар. Ә энәләренә алмалар тезелгән түгәрәк әйбер шулчак йөгерә башламасынмы! Алай гынамы әле, ул ахмак маймыл балаларын мыскыллап көлгән дә. Маймыл балалары ялгышларын аңлаганнар: бу аңлаешсыз әйбер дикобраз икән бит. Ул чәнечкеле куак янында утырган һәм зиһенсез маймыл балалары аны чәнечкеле зур җимеш дип кабул иткәннәр.

Аркасына алмалар тезелгән дикобраз тиз генә качып киткән. Ай күрде, кояш алды кебек кенә булган. Ул балаларына өлгергән җимешләр ашаткан һәм шуннан соң ахмак маймыл балаларын да сыйлаган.



Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМ



ДВЕ ОБЕЗЬЯНКИ

(Индийская народная сказка)

В одном городе жили две обезьянки и были они очень рассеянные. Обе были большие охотницы до фруктов, ведь они очень вкусные и полезные: будешь есть фрукты — станешь красивым и ловким.

Однажды обезьяны отправились побродить по лесу и увидели там большую яблоню со спелыми плодами. Им захотелось взять домой побольше яблок. Но во что их положить?

Посмотрели обезьяны по сторонам и увидели под кустом какой-то круглый предмет, похожий на шар, весь усаженный иглами. Обезьяны очень обрадовались и стали катать шар по земле, которая была усыпана спелыми яблоками. Когда все плоды оказались на иглах, радостные обезьяны забрались на дерево и, нарвав самых лучших яблок, побросали их вниз. А круглый предмет с яблоками на иглах вдруг побежал! Мало того, он стал насмехаться над глупыми обезьянами. Поняли обезьянки свою ошибку, ведь непонятный предмет оказался дикобразом. Он сидел около куста с колючками, и рассеянные обезьяны приняли его за большой колючий плод.

Дикобраз быстро убежал с яблоками на спине. Только его и видели. Он накормил своих детей спелыми плодами, а потом все-таки угостил и глупых обезьян.




Художник ЗАГИР ХАКИМОВ




КИТЛАР

Китларның балыклар түгел, ә имезүчеләр икәнлеген хәзер һәркем белә. Балыклардан аермалы буларак, китлар җылы канлы, үпкәләр белән сулыйлар, тере балалар тудыралар һәм аларны сөт белән тукландыралар. Өстәвенә, бөтен китлар да зур, катлаулы төзелешле баш миенә ия һәм үсешнең югары баскычында торалар. **Күк буй-буй кит (зәңгәр кит)** — дөньядагы иң зур хайван. Аның авырлыгы 30 фил авырлыгына тигез — 150 тонна тирәсе. Озынлыгы — 30 метрга кадәр. Күләме белән ул иң эре динозаврдан да зуррак булып чыга. **Кашалот** — китсыманнар семьялыгының эре вәкилләреннән берсе (озынлыгы 19 метрга җитә), ул Америка яр буйларында тереклек итә. Аны башка китлардан башының квадрат формасы буенча җиңел аерырга мөмкин. Кашалот — иң оста йөзүче һәм шәп чумучы. Азык эзләп ул 35 метр диярлек тирәнлеккә төшә, әмма аның, сулыш алу һәм чыгаруда 2 сәгатьлек пауза ясап, 1000 метрдан тирәнрәккә төшү очраклары да билгеле. **Өркәчле кит** су астында җырлавы белән атаклы. Өркәчле китларның чутылдавы кошлар сайравыннан да күптөрлерәк, ә авазлары су катламында берничә километрга тарала.



Кайвакыт аларны су өслегендә дә ишетеп була. **Соры кит** — зур сәяхәтче. Ул елга ике мәртәбә бөтен Төньяк Америка ярлары буенча йөзеп үтә. Аны юлга нәрсә әйди соң? Эш шунда ки, соры кит өчен азык Арктикада гына бар, ә үрчүен ул көньяк киңлекләрнең җылы сай сулыкларында үрчи, менә шуңа күрә аңа бер урыннан икенче урынга күчеп йөрергә туры килә. Галимнәр ачыклавынча, китлар сәяхәтләре вакытында диңгездә теләсә нинди һава торышында — шторм һәм тынлыкта (штильдә), тирәндә һәм су өслегендә, көндез һәм төнлә дә искиткеч оста ориентлашалар. Аларга анализаторлар дип йөртелүче сизү әгъзалары ярдәм итә икән.



Рәссам АРТУР ХӘКИМ

КИТЫ

Сейчас все знают, что киты — не рыбы, а млекопитающие. В отличие от рыб киты теплокровны, дышат легкими, рождают живых детёнышей и выкармливают их молоком. Кроме того, все киты обладают крупным, сложно устроенным мозгом и стоят на высокой ступени развития. **Синий полосатик (голубой кит)** — самое крупное в мире животное. Вес синего полосатика равен по весу 30 слонов — около 150 т. Длина — до 30 м. Получается, что по размеру он больше самого крупного динозавра. **Кашалот** — один из крупнейших представителей семейства китовых (его длина достигает 19 м), обитает у берегов Америки. Его легко отличить от прочих китов по квадратной форме головы. Кашалот — непревзойдённый пловец и отличный ныряльщик. В поисках пищи он погружается на глубину почти 35 м, но известны случаи, когда он спускался более чем на 1000 м, с паузой между вдохом и выдохом около 2 часов.



Горбатый кит (горбач) знаменит тем, что он поёт под водой. Трели горбатых китов разнообразнее пения птиц, а звуки часто разносятся в толще воды на несколько километров. Иногда их слышно и на поверхности. **Серый кит** — большой путешественник. Дважды в год он совершает «заплывы» вдоль всего побережья Северной Америки. Что же гонит его в путь? Дело в том, что еда для серого кита есть только в Арктике, а размножается он на мелководье в тёплых южных широтах, вот и приходится перебираться с места на место. Ученые установили, что во время своих путешествий киты умеют прекрасно ориентироваться в море при любой погоде — в шторм и штиль, на глубине и у поверхности воды, днём и ночью. Оказалось, что помогают им так называемые анализаторы — органы чувств.



Художник АРТУР ХАКИМОВ


Рәссам ИЛДУС ӘҖЕМ

КОРОЛЁК ҺӘМ АЮ

(Немец халык әкияте)



Бервакыт җәй көне аю һәм бүре урманда йөрергә чыкканнар. Аю ниндидер кошның искиткеч матур итеп сайравын ишетә дә бүредән нәрсә сайравын сорый. «Бу бөтен кошларның короле — королёк»,— дип җавап бирә бүре. Аю әлеге кош оясының кайда булуын исендә калдыра да озакламый шунда яңадан килә. Ә бу вакытта кошлар короле һәм королева еракка очып киткән булалар. Аю, ояга күз салгач, анда кошчыклар ятуын күрә. «Сарай шыксыз икән ләбаса! Ә сез король балалары түгел, ә ташландык балалар!» — дип гаҗәпләнүдән кычкырып җибәрә аю. Моны кайтып килүче королёк ишетеп ала да: «Әй, карт мыгырдавык, син нигә минем балаларымны рәнҗеттең? Сиңа сугыш игълан итәм»,— дип кычкыра.

Аю сугышка бөтен җәнлекләрне чакыра, ә королёк һавада очучы барлык нәрсәләрне, — кошларны гына түгел, черкиләрне, төклетураларны һәм чебеннәрне дә ярдәмгә чакыра.

Менә сугыш көне җитә. Королёк черкигә дошманнарның генералы кем булуын белергә куша. Черки җәнлекләр гаскәре янына очып килә, ә бу вакытта аю: «Төлке, син иң хәйләкәре, син генерал булырга тиеш»,— ди. Төлке ризалаша: «Әгәр мин җирән койрыгымны өскә каратып тотсам, димәк, барысы да яхшы, ә инде койрыгымны төшерсәм — күзләрегез караган якка качыгыз». Черки моны ишетеп ала да королёкка җиткерә.

Королёк төклетураны төлкенең койрыгын тешләргә җибәрә. Беренче мәртәбә тешләгәч, төлке сискәнеп китә, әмма койрыгын югары тотуын дәвам итә. Әмма икенче мәртәбә тешләүгә койрыгын төшерергә туры килә. Җәнлекләр, моны күргәч, таю ягын карыйлар. Ә королёк: «Әй, аю, минем ояга бар да, балаларымнан кичерү сора!» — дип кычкыра.

Аю кошчыклардан бик озак гафу үтенә. Яшь королёклар, аны кичереп, төн уртасына кадәр күңел ачалар.



КОРОЛЁК И МЕДВЕДЬ

(Немецкая народная сказка)

Однажды летом пошли медведь и волк в лес погулять. Услыхал медведь прекрасное пение какой-то птицы и спросил у волка, кто это поёт. «Это король всех птиц — королёк»,— сказал волк. Запомнил медведь, где находится гнездо, и вскоре пошёл туда опять. А в это время король птиц и королева далеко улетели. Заглянул медведь в гнездо, видит — лежат в нём птенцы. «Ну и неказистый же дворец! А вы и вовсе не королевские дети, а подкидыши!» — воскликнул медведь. Услыхал это возвратившийся королёк и закричал: «Эй, старый ворчун, ты зачем обидел моих детей? Объявляю тебе войну».

Созвал медведь на войну всех зверей, а королёк призвал всех, кто летает в воздухе,— не только птиц, но и комаров, шмелей и мух.

Настал день битвы. Выслал королёк комара узнать, кто у врагов генерал. Комар подлетел к звериному войску, а медведь в это время говорит: «Лис, ты самый хитрый, ты должен быть генералом». Лис согласился: «Если я буду держать свой рыжий хвост вверх — значит, всё хорошо, а если я опущу хвост — бегите куда глаза глядят». Услыхал это комар и передал корольку.

Послал королёк шмеля, чтобы укусить лиса за хвост. Получил лис первый укус, вздрогнул, но продолжал держать хвост высоко. Да при втором укусе пришлось ему хвост опустить. Увидали это звери и пустились бежать наутёк. А королёк крикнул: «Эй, медведь, ступай к моему гнезду, проси прощения у моих деток!»

Долго извинялся медведь перед птенцами. Простили его молодые корольки и веселились до самой глубокой ночи.





Художник ИЛДУС АЗИМОВ



Айфираз Зарифуллин

БЕЗНЕҢ ЙОРТ

(Хикәя)

Илдар инде зур, бакчага йөри. Аның бакчада дуслары да бар. Дусларының исеме Марат һәм Маша. Алар бергә уйныйлар.

Марат күрше йортта яши. Маша ераграк тора. Башта юл аша чыгарга кирәк, аннан Машаның йорты ерактан ук күренеп тора икән. «Безнең йорт шундый биек, өскә карагач, башымнан эшләпәм төшә»,— ди ул.



Беркөнне бакчадагы мәйданчыкка уйнарга чыккач, Маша аларны үзләренең йортын күрсәтергә алып китте. Тәрбияче апалары киткәннәрен күрми дә калды. Бик озак йөрде алар. Машаның йорты күренми дә күренми. Маша елап җибәрде. Марат та мышык-мышык килә башлады. Ә Илдар еламады. Ул үзләренә таба йөгерүче тәрбияче апаны күреп алды.





Рәссам ИЛДАР ӘХМӘДИ



Художник ИЛДАР АХМАДИЕВ



Айфираз Зарифуллин

НАШ ДОМ

(Рассказ)

Ильдар уже большой. Он ходит в детский сад. У него в садике есть друзья. Их зовут Марат и Маша. Они играют вместе.


Марат живет в соседнем доме. Маша живет подальше. Сначала надо перейти через дорогу, а там уже Машин дом виден издалека. «Наш дом такой высокий, когда смотрю вверх, с головы шляпка падает», — говорит она.

Когда они вышли играть на площадку, Маша решила показать им свой дом. Воспитательница даже не заметила их уход. Долго ходили они. Машин дом так и не виден. Маша уже начала плакать. Марат тоже начал всхлипывать. А Ильдар не заплакал. Он заметил, что к ним бежит воспитательница.



Гөлназ: Без Пони белән гел бергә йөрибез, бер-беребезне хөрмәт итәбез!

Гульназ: Мы с Пони неразлучники, куда он, туда и я.



Илдус: — Әби-бабай! Без Акбай белән «Мирас» журналының һәр санын укып барабыз! Сез дә шулай итәсезме?

Әби-бабай: — Без дә бу милли энциклопедияне бик яратабыз!

Индекс 73954

МИРАС



Рәссам СВЕТЛАНА ФӘТТАХОВА

Художник СВЕТЛАНА ФАТТАХОВА

Цена договорная